АЛТЫН УРТАЛЫК
Ришвәт бирми-алмый гына да ярдәм итеп була

> 2

БЕЗ БЕРГӘ
Казахстан белән Татарстан мөнәсәбәтләре нигезендә дуслык ята

> 3

СОҢГА КАЛМЫЙК
Балалар белән террорчылык турында сөйләшкәндә нәрсәне истә тотарга?

> 3

КӨЛ...МӘ!
Камал театрында – япон драматургиясе

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 158 (28931) | Чәршәмбе | 26 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КОТКАРУ БОҖРАСЫН КЕМ БИРЕР?

ТАТАРСТАНДА ХАЛЫК САНЫ КИМИ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вазгыять

2050 елга республика халкы 100 мең кешегә кимергә мөмкин. Татарстан Фәннәр академиясенең гаилә һәм демография үзәге белгечләренең быел игълан иткән фаразлары бу. Ачы хакыйкать чынга ашып маташа бугай инде. Татарстанстат китергән санлы мәгълүматларга ышансаң, республикада яшәүчеләр саны, узган елгы күрсәткечләр белән чагыштырганда, кими башлаган.

Санлы фаразлар

Иң элек 2021 елгы саннарга күз салыйк. Бу вакытта республикада 3 894 120 кеше яши дип исәпләнгән. Шуларның 2 994 450се – шәһәр халкы. Район-авылда яшәүчеләр – 899 670 кеше. Быелгы саннар үзгәрәк. 2022 ел башына республикада яшәүчеләр саны 3 886 395не тәшкил итә. Шәһәрдә яшәүчеләр саны 2 986 674 булса, район-авыл халкы – 899 721 кеше.

Куандыра торган күренеш бар: сала халкы арткан. Әмма ике ел күрсәткечләрен чагыштырып карасак, халык саны 7725 кешегә (0,2 процентка) кимегән булып чыга.

Сүз уңаеннан, мондый статистика икенче ел күзәтелә инде. 2020 елны искә алсак, республикада яшәүчеләр саны 0,22 процентка яисә 8,77 мең кешегә кимегән иде. Ә моңа кадәр, 2007 елдан башлап, Татарстан халкы артып торды. Әйтик, 2016 елда арту күрсәткече 16,52 мең кешегә җиткән иде.

Нишләргә?

Кимүне ничек туктатырга соң? Хәер, бу инде мәңгелек сораугa әйләнеп бара һәм аңа җавап та күптән билгеле кебек. Белгечләр дә халык санын арттыруның төп юлларын икътисади һәм геосәяси тотрыклылык, иртәгәге көнгә ышаныч булуда, яңа гаиләләр оешуда күрә. Бу күрсәткечләргә ирешәбез икән, гаиләләрдә балалар да туачак, кешеләрнең сәламәтлеге дә булачак, гомер озынлыгы да кисәк кенә кимемәячәк. Салага гына яисә калага гына таянырга ярамый.

Татарстанның 2017–2028 елларга Бюджет фаразы мәгълүматларына караганда, республикада даими яшәүчеләр саны 2030 елга 3 899 800гә җитәргә тиеш. Төбәктә мондый уңай динамикага миграция үсеше һәм туучылар саны арту хисабына ирешергә мөмкин, дип ышаналар.

Ахыры 2 нче биттә >

ФИКЕР

Роберт ГОРДЕЕВ, Буа районындагы Ырынгы (Рунга) авылы җирлеге башлыгы:

– Бездә бәхетле яшәү өчен барлык шартлар да тудырылган. Соңгы елларда төзекләндерү эшләре күп башкарылды. Яңартылган мәдәният йорты да, китапханә дә, урта мәктәп тә бар. Спорт һәм балалар мәйданчыклары эшли. Юллар да төзек. Зиратны да тәртиптә тотабыз. Үзара салым акчасының файдасын күрәбез. Ярдәмләшеп тора торган хәлле авылдашлар да бар. Салада яшәрлек, аны яшәтерлек шартлар бар, кыскасы. Киләчәк өчен эш күп, планнар зурдан. Шәһәр халкы да авылга тартыла башлады. Буш торган йортларны сатып алып, бирегә кайтып төпләнүчеләр бар. Алар кайткач, бала-чагасы да кайта, билгеле. Җәйге вакытта алар да авылдагы китапханәгә, уен мәйданчыкларына йөри. Әбибабайларына кайткан шәпкә биредә балалар бакчасын, мәктәпне тәмамлаган балалар да бар әле. Гомумән, шәһәр фатирын калдырып торып, авылны сайлау тенденциясе күзәтелә.

Рамил МӨХЕТДИНОВ, «Җидегән чишмә» Арча театры җитәкчесе (Наласа):

– Статистикага күз салсаң, безнең җирлектә бераз кеше кимегән булып чыга. Бу саннарга карап аптырап калдым әле. Әмма статистикага каршы барып булмыйдыр. Ләкин безнең авылны, башкалары белән чагыштырганда, үсештә дип саныйм. Ул район үзәгенә дә якын. Әйтик, минем өйдән эшкә баруым – нибары 11 чакрым. Авылда яшьләр саны да аз дип булмый. 11 еллык мәктәп, өр-яңа балалар бакчасы бар, 40 урынга исәпләнгән. Белем ала, тәрбияләнә торган балалар – барысы да Наласаныкы бит! Яңа өйләр салалар. Әйтик «Сервис агро» ширкәтенә караган «Игенче» агрофирмасы үз хезмәткәрләренә биш өй салып бирде. Моннан тыш та йорт салучылар күп. Инфраструктура бар бит. Тырышып, горурланып яшәргә генә кирәк!

80 кеше кала

Татарстанда мобилизацияләнгән күпбалалы 80 ир-егет өйләренә кайтачак. Билгеле булганча, узган атнада Татарстанның Чакырылыш комиссиясе андыйларны хәрби хезмәттән азат итү турында карар чыгарды. Шунысы да бар, күпбалалы кайбер ир-егетләр, мондый мөмкинлектән баш тартып, махсус хәрби операция зонасына ихтыярилар булып юл тотачак. Өйләренә кайтып китүчеләр урынына исә яңа кешеләр җыячаклар.

Тиененә кадәр алмыйлар

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе бурычлы 3,3 меңнән артыграк кешенең счетларында хезмәткә түләүнең минималь күләмендә (МРОТ) акча калдыру турында гаризасын канәгатьләндергән. Исегезгә төшерәбез: финанс мәсьәләсендә авырлык кичерүчеләр, әҗәтләрен түләткәндә, банк счетында МРОТ күләмендә акчасын саклап калу хокукына ия.

Хәзер бурычлылар акчаларының бер өлешенә кагылмау турында гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы аша да тапшырырга мөмкин. Моңа кадәр суд приставлары хезмәте бүлегенә мөрәҗәгать итәргә яки гаризаны почта аша юлларга кирәк иде. Моннан тыш Суд приставлары федераль хезмәтенең үтенечләр тапшыру сервисыннан да файдаланырга мөмкин.

Яшьләргә – акча

Татарстанга яшьләр сәясәтен үстерү өчен федераль үзәктән 136,5 миллион сум акча җибәреләчәк. Росмолодежь, төбәкләрдә яшьләр сәясәтен комплекслы үстерү программасын эшләп, аны тормышка ашыруга керешкән.

Барлыгы 42 төбәккә субсидия биреләчәк. Алар «Регион для молодых» бәйгесе (51 төбәк катнашкан) йомгаклары буенча сайлап алынган. Бәйге комиссиясенә хакимият органнары, бизнес вәкилләре, коммерциясез оешмалар җитәкчеләре кергән.

Яшьләр сәясәтен үстерүгә акча алачак төбәкләр арасында күрше республикалар – Башкортстан (227,8 миллион), Удмуртия (153 миллион), Түбән Новгород өлкәсе (256,7 миллион), Мари Иле (122,2 миллион), Мордовия (112 миллион) һ.б. бар.

Солдатларга – хәләл ит

Диния нәзарәте Казан танк полигонына Татарстаннан махсус хәрби операциягә чакырылган егетләр өчен тәгаенләнгән ярдәмнең бер өлешен китергән. Мөселман солдатларга барлыгы 2,5 тонна йөк тапшырылган. Гуманитар ярдәм асылда 7848 банка хәләл ит консервыннан тора. 7056 данәсен нәзарәтнең «Зәкят» фонды сатып алган, 792сен Арча районы, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәтләре җибәргән. Моннан тыш хәрбиләргә 30 данә матрас һәм 30 пар җылы эчке кием бирелгән.

Солдатларга ярдәмне, «Без бергә!» бөтенроссия акциясе кысасында, «Ярдәм янәшә!» республика иҗтимагый хәрәкәте оештырган. Татарстаннан мобилизацияләнүчеләргә хәләл ризык республикада игълан ителгән «Ярдәм янәшә!» кампаниясе кысасында да юлланачак.

Исегезгә төшерәбез: республиканың төрле почмакларында яшәүче мәрхәмәтле кешеләрнең ярдәме, аеруча мөхтәсибәтләрнең тырышлыгы белән Татарстан мөфтияте 5,1 миллион сумнан артыграк күләмдә акча җыюга ирешкән. Шуның 2,5 миллион сумына 14 000 данә (барлыгы 5 тонна) хәләл ит консервы сатып алынган.

Ризык 325әр граммлы калай банкаларга тутырылган. Ул егетләргә үзләре белән йөртү өчен бик уңайлы булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшәргә өйрәнәбез

Ярдәм берләшә

Киләсе ел башыннан Россиядә аз керемле гаиләләргә универсаль пособие түләнә башлаячак. Яңа төрле ярдәм түгел ул. Моңарчы булганнарын берләштереп түли башлаячаклар. Универсаль пособие 6 ярдәм чарасын берләштерәчәк. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган брифингта Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин сөйләде.

– Пособие гаиләдә җан башына тиешле керем яшәү минимумыннан түбән булганда, хатын-кызларга, 17 яшькә кадәрле бала үстерүчеләргә билгеләнә. 2023 елда яшәү минимумы 12 мең 219 сум булыр дип фаразлана. Пособиене билгеләгәндә, гаиләнең еллык кереме исәпләнәчәк. Әйтик, 12 мең 219 сумны 12 айга тапкырласаң, 146 мең 628 сум килеп чыга. Әгәр гаиләдә 4 кеше яши икән, бу сумманы 4кә тапкырлыйсы була. Керемегез килеп чыккан суммадан азрак икән, сез дәүләт ярдәменә өметләнә аласыз, – ди Эдуард Вафин.

8 яшьтән 17 яшькәчә балалар өчен бирелә торган пособиене билгеләгәндә исә айлык хезмәт хакы, эшмәкәрлектән кергән табыш кына түгел, пенсия, стипендия, милек, торак саткан, арендага биргәннән кергән акча, кертем буенча процентлар да машина, гараж, җирләр дә исәпкә алыначак. Мондый милеге булганнар пособиегә өметләнә алмый.

Очрашуда илдәге вазгыятьне күз уңында тотып та сорау бирүчеләр булды. Әйтик, бала үстерүче әниләр ирләрен махсус операциягә озатты. Кайберләренә инде хезмәт хаклары, дәүләт ярдәмнәре килә башлады. Әлеге

Илдар Мөхәммәтҗанов

акча гаиләнең табышы булып саналамы? Пенсия идарәсе белгечләре ул акчаның исәпкә алынмаячагын белдерде. Әмма 2023 елда ниләр буласын алдан әйтә алмауларын да җиткерделәр.

Шунысы да бар: әлеге пособиене алу өчен ирнең дә, хатынның да эш урыны, кереме булу кирәк. Эшләмәгән очракта нишләргә? Эдуард Вафин, андыйларның кулында белешмә булырга тиеш, ди. Ул бала белән декрет ялында яки авыру тәрбияләп эшли алмау турында булырга мөмкин. Җитәкчеләр, ярдәмгә мохтаҗ булган берәү дә читтә калмаячак, дип ышандыра.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Сергей КИРИЕНКО, Россия Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары:

Россия укучыларының 80 проценттан артыгы мәктәпләрдә дәүләт флагын күтәрү һәм гимнны башкаруны хуплый. Бу балаларның үзләре өчен дә бик кирәк. Әти-әниләр дә моның ни дәрәҗәдә мөһим булуын аңлый.

(Бөтенроссия сыйныф җитәкчеләре форумыннан)

КАЙДА КҮПМЕ ТҮЛИЛӘР?

Кайсы тармакта хезмәт хакы югары, ә кайсында бик түбән. Росстатның соңгы мәгълүматлары шуңа ачыклык кертте.

РОССИЯДӘ УРТАЧА ХЕЗМӘТ ХАКЫ (мең сум) – 62,2

Кайсы өлкәләрдә күпме түлиләр	(мең сум)
Финанс һәм иминиятләштерү	136,5
Файдалы казылмалар табу	125,1
Балыкчылык	95,5
Металлургия	74,3
Кәгазь җитештерү	64,5
Төзелеш	60,6
Сәүдә	55,1
Спорт, мәдәният	54,2
Авыл хуҗалыгы	42,9
Мәгариф	32,3
Кием җитештерү	26,5



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГАРӘП БИЗМӘНЕ

Дөнья сәясәтендә хәлиткеч адымнар ясар алдыннан президентлар һәм корольләр, бизнес элитаның күренекле вәкилләре үзара тел сугышы алып бара. Американың көндәлек газетасы The Wall Street Journal Согуд принцы Мөхәммәд ибн Салманның Байденнан көлүе, аның акыл сәләтенә шикләнеп караvы турында яза.

Газета хәбәренә ышансаң, быелның июль аенда Әр-Риядка килгәч, Байден принцның җен ачуын чыгарган. Вашингтон лидеры Согуд Гарәбстанында кеше хокуклары бозылу турында сөйләнеп, ике арадагы мөнәсәбәтләрне тәмам бозып бетергән. Мөхәммәд ибн Салмән Американың соңгы президентлары арасыннан бары тик Трамп белән генә аралашырга яраткан, имеш. Байден белән Обама исә аның мөнәсәбәтен яулый алмаган. Традицион рәвештә гарәпләр республикачы президентларны үз итә, ә демократлар АКШ дилбегәсен кулга алганда артык дустанә мөнәсәбәтләр кормыйлар. Американнарга исә бүгенге катлаулы вазгыятьтә Әр-Рияд белән араның нык һәм яхшы булуы кирәк.

Бу атна башында Әнкара Согуд Гәрәбстанын яклау ягына күчте. Әле кайчан гына төрекләр белән гарәпләр шулай ук үзара дошманлашып беткәннәр иде, әмма Төркия хәлне тәзәтү юлына басты. «Согуд Гарәбстаны куркыту урынсыз. Без дә, энергия чыганакларына бәяләр үсү сәбәпле, шундый ук проблемалар белән очрашабыз, әмма беркемгә дә янамыйбыз», – диде Төркиянең тышкы эшләр министры Мәүлүт Чавушоглу Вашингтонга карап. Аның фикеренчә, нефтькә һәм газга бәяләрнең югары булуында Венесуэлага һәм Иранга америкаларның керткән санкцияләр гаепле. «Әгәр дә нефтькә бәяләр төшсен дисәгез, санкцияләрне алыгыз», – диде ул. Сәясәт сәхнәсе артыннан алынган хәбәрләргә караганда, Әр-Рияд Әнкарадан ОПЕК+нең нефть чыгаруны киметү турындагы карарын яклауны сораган. Төрекләр 20 миллиард долларлык Согуд инвестициясенең үз банкларына күчүен көтә. Гарәпләрне яклауның бер сәбәбе шунда.

Кытай югары җитәкчелегендә мөһим карар кабул ителде. Илнең тышкы эшләр министры Ван И компартиянең Үзәк Комитетына кертелде һәм чын мәгънәсендә Пекин дипломатиясенең йөзен билгеләүчегә әйләнеп бара. Эш шунда: чиннарда тышкы эшләр министры икенче дәрәҗәдәге техник фигура булып санала. Тышкы сәясәтне компартия Үзәк Комитетының тышкы эшләр буенча канцеляриясе җитәкчесе билгели. Хәзер канцелярияне Ян Цзечи җитәкли, әмма аңа 72 яшь инде һәм ул лаеклы ялга китәргә җыена. Аның урынын Ван И алыр, диләр. Ван Ига да – 68 яшь, компартиядә кабул ителгән кагыйдәләр буенча бу яшьтә югары вазыйфаларга билгеләмиләр. Ләкин Ван И – Си Цзиньпинның якын дусты һәм аның өчен искәрмә булачак, дип әйтәләр. Тышкы эшләр министрын япон матбугатында «сугышчы бүре» дип атап йөртәләр икән. Кырыс һәм агрессив тышкы сәясәт остасы булачак таныйлар. Димәк, Кытайның тышкы сәясәтендә агрессивлык артачак. Пекин Америка гегемонлыгы өчен тагын бер каты чикләвеккә әйләнер, мөгаен.

Россиядә

ИРАН БЕЗГӘ БУЛЫШЫР

Финанс мәгълүматлары сатып яшәүче Bloomberg агентлыгы, Россия нефтен экспортлау кими, дип яза. 14–21 октябрь аралыгындагы атнада бюджетның нефть сатудан кергән керемнәре 24 процентка соңгы чорда иң түбән дәрәҗәдә, ди ул.

Һиндстанга нефть сату кыйммәткә төшә, чөнки Россиядән Һиндстанга кадәр араны танкерлар 2,5 атнадан алып бер айга кадәр вакыт эчендә уза. 5 декабрьдә Европа берлегенең «кара алтын»га бәйле санкцияләре гамәлгә керәчәк, шул сәбәпле Дәһли ноябрьдә Россия нефтен алуны бөтенләй туктатырга җыена, чөнки җир мае 5 декабрьдән соң гына Һиндстанга барып җитәчәк. Дөрес булса, Кытай да Россия ташкумерен һәм нефтен сатып алуны сентябрьдә киметкән икән. Ташкүмер импортлауны 19 процентка, чи нефть алуны 10,5 процентка кыскан. Аңлашыла инде: нефть-газ керемнәре саега. Җитмәсә, Европа базарында газга бәя мең кубометрга мең доллардан түбәнгәрәк төште һәм бу тенденция дәвам итә.

Россия гаиләләренең керемнәре болай да мактанырлык түгел. Зур уңыш һәм сөт савуның артуына карамастан, халык сөт продуктлары һәм балык кулланыну киметкән. Сәламәтлек саклау министрлыгы елга бер кешегә уртача 325 килограмм сөт продуктлары кулланырга киңәш итсә, 2021 елда ул 265 килограмм гына булган.

Махсус хәрби операция, мобилизация икътисадка да, бюджетка да йогынты ясый. Җитмәсә, санкцияләр нәтиҗәсендә технологик җиһазлар табу кыенлаша. Бу сәнәгать җитештерүен үстерергә комачаулый. Чит ил компанияләре киткәч, әчке базарлар да кинәйде югыйсә. Үсеш өчен башка аркадашлар табарга туры килә. Иран технологик продукция белән Россияне тәэмин итүче донорга әверелеп бара. Фарсыларга санкцияләрдән куркасы юк, чөнки болай да бикләнеп яшәргә мәҗбүрләр. Ә менә Россия базары алар өчен алтын янгыры яудыра ала. Тәһран бездән чимал ала, безгә бик теләп технологик продукция озата. Үзләренең газ сәнәгате өчен җиһазларны фарсылар нигездә үзләре җитештерә һәм безнең белән дә бик теләп уртаклаша. Якындагы арада көньяк күршедән безгә 40 газ турбинасы киләчәк икән. Моңарчы Россия кечерәк куәттәге газ кудыру җиһазларының өчтән берен – Чехиядән, 30 процентын – Канададан, 22 процентын – АКШтан, 8 процентын – Франциядән, 4 процентын Украинадан алган. Куәтле турбиналар исә АКШтан, Бөекбританиядән, Швециядән, Япониядән килгән. Газ кудыру җиһазлары йөз процентка диярлек импорттан алынган. Бик тиләгәндә дә бу өлкәдә импортны үз продукциябез белән алыштырып бетерә алмаячакбыз, ди белгечләр. Иран җиһазлары исә ышанычлы, ватылмыйлар, дип белдерәләр. Технологик продукция сорап, фарсылар карышына бару бик үкенечле инде, нишләтәсең. Автозапчастьларны да шулардан алырга җыенабыз бит. Икенче яктан ул өметләндерә дә. Блокада шартларында Иран үсә алган икән, без ник булдыра алмаска тиеш?!

УФАДА ИКЕ ПАРЛАМЕНТ КИЛЕШТЕ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Идел буе федераль округы субъектларының дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясе утырышында катнашты. Чара Уфада узды. Парламентчылар цифрлаштыру, дәүләт һәм муниципаль контрольне оештыру, яшьләр парламентаризмын үстерү мәсьәләләрен карады. Утырыш кысасында шулай ук Татарстан Дәүләт Советы белән Чувашия Дәүләт Советы арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.

Ассоциация утырышында цифрлаштыру мәсьәләләре аерым игътибар үзәгенә алынды. Төбәкләрдә банк өлкәсендә, шулай ук дәүләт идарәсендә күп кенә эшләрне җиңеләйтү мөмкинлеге бирердәй цифрлы инфраструктура булдырыла. Утырыш алдыннан парламентчылар Башкортстан Республикасы Идарә үзәгендә (быел март аенда ачылган) булды. Үзәк эшенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе – территорияне комплексы идарә итү һәм халык белән кире элемтә оештыру.

tatarstan.ru

Безнең республикада Цифрлаштыру елында цифрлы үзгәрешләр дәвам итә, тормышыбызның барлык өлкәләре шул форматка күчә. Бәшир Рәмиев исемендәге IT парк ачу Татарстанның цифрлы индустриясен үстерүдә яңа ноктага әйләнде. Бик мөһим буруч – цифрлаштыру өлкәсендә шәһәр белән авыл арасындагы тигезсезлекне юкка чыгару бурычы хәл ителә, иң ерактагы авылларга да югары тизлекле интернет үтеп керә. Татарстанда яшәүчеләр барлык дәүләт хезмәтләренең 60 процентын чамасын электрон рәвештә ала. «Бүген цифрлаштыру, мәгълүмат алу мөмкинлеге мәсьәләләре – чиктән тыш мөһим. Иртәгә аларның әһәмияте икеләтә артачак, – дип билгеләп үтте Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин журналистлар белән әңгәмәсендә. – Хакимият органнарының һәм депутатларның эш нәтиҗәсенә дә кагыла бу. Бүгенге катлаулы шартларда ил Президенты Владимир Путин тирәсендә берләшергә тиешбез. Ассоциация мәйданчыгы моны тизрәк хәл итү мөмкинлеге бирә».

Идел буе төбәге закон чыгаручылары дәүләт һәм муниципаль контроль системасын үзгәртеп кору мәсьәләләренә аерым тукталды. Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров әйтүенчә, округ төбәкләренең күпчелегендә эшмәкәрлек субъектларының, элеккечә үк, бик еш тикшерелүе теркәлә. «Хакимиятнең барлык баскычларында билгеләнгән чикләүләрнең үтәлешен күзәтергә һәм контроль мәсьәләсендә чама хисен югалтмаска кирәк», – диде вәкаләтле вәкил. Шул ук вакытта Игорь Комаров кабул ителгән чикләүләрне үтәү буенча Татарстаны үрнәк төбә буларак телгә алып үтте.

Ассоциация эше барышында Татарстан Дәүләт Советы белән Чувашия Дәүләт Советы арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Документка Татарстан һәм Чувашия парламентлары башлыклары – Фәрит Мөхәммәтшин белән Леонид Черкесов кул куйды.

«Моңа кадәр дә нык элемтәләребез бар иде. Хәзер исә законнар иҗат итү эшендә бер-беребезгә ярдәм итү буенча җаваплылык алдык», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

КОТКАРУ БОҖРАСЫН КЕМ БИРЕР?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Миграция димәктән, соңгы елларда ил-көнне уаулыкка сынап торган вакыйгалар бу күренешкә дә йогынты ясамый калмады, билгеле. Коронавирус пандемиясе котырган вакыт, дисеңме, хәзер исә – өлешчә мобилизация, хәрби операция шаукымы. Шулай да Татарстанның бу юнәлештә, башка төбәкләр белән чагыштырганда, хәле яхшырак: 2022 елның беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре буенча республикада миграция үсеше теркәлгән һәм 3778 кешене тәшкил иткән. Бу – узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 10 процентка артыграк дигән сүз. Былтыр бу сан 3440 иде.

Ә балалар туу ни бирер? Татарстан Фәннәр академиясенең гаилә һәм демография үзәге әзерләгән фаразларга караганда, 2033 елга республика халкы 4,4 миллион кешегә җитәргә тиеш дигән өметләр булган.

– Моңа репродуктив, ягъни нәсел калдырырга сәләтле контингент өлеше арту бәрабәренә ирешергә мөмкин иде, – ди үзәк директоры, социология фәннәре докторы Чулпан Илдарханова. – 2020 ел исә барысына да үзгәрешләр кертте. 12,9 меңләп кешегә кимедек. Пандемия демографиягә бәйле киләчәкне тагын да томанландырды.

Бала табып кына халык саны артуга әллә ни ирешеп булмаячак, дип саный белгеч. Ник дигәндә, 1990 елларда «демографик упкын» буыны үсеп җитте. 1990 елдан башлап туган кыз балалар – булачак аналар санына таянып фаразласак, 2033 елга кадәр Татарстанда бәби алып кайтучылар саны кимеячәк. Шулай да, республика өчен әле дә баласызлык сирәк күренеш булып кала бирә.

Хатын-кызларга гына булса икән хикмәт. Белгечләр, ир-атларның үлем очраклары күп булу демография фаҗигасенә илтергә мөмкин, дип фаразлый. Бу исә ир-ат сәламәтлеген кайгырту юнәлешендә медицина мөмкинлекләрен көчәйтүне дә сорый. Кыскасы, аларны да кадерләр чак җитте.

Ана капиталын яңартырга, ир-атлар үлемен киметергә. Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе белгечләре ил күләмендә кеше санын арттыру буенча шундый тәкъдимнәрен җиткергән иде. Бер караганда, кайсы төбәккә дә батарлык кагыйдәләр инде бу. Академия белгечләре әйтүенчә, кешеләргә үзләренең икътисади һәм репродуктив мөмкинлекләрен тулысынча чыгара алырлык шартлар тудыру кирәк. Сәламәтлек саклау тармагында да үзгәрешләр таләп ителә. Нигездә физик активлык, дөрес туклану, сәламәт яшәү рәвеше кебек чаралар булырга тиеш. Моңа исә мотивация кирәк. Социаль гарантияләр, матди ярдәм чараларының әһәмияте турында әйтеп тору да кирәкмидер.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫНДА 2022 ЕЛ БАШЫНА ХАЛЫК САНЫ

Район исеме	Халык саны		
	барлыгы	шул исәптән калада	шул исәптән авылда
Азнакай	57765	41157	16608
Аксубай	26959	9573	17386
Актаныш	28148	-	28148
Алабуга	85825	74181	11644
Алексеевск	24522	11695	12827
Апас	18954	5398	13556
Арча	49798	20018	29780
Әгерҗе	33936	19628	14308
Әлки	18177	-	18177
Әлмәт	207966	168492	39474
Әтнә	12532	-	12532
Балтач	32774	8402	24372
Баулы	33196	21372	11824
Балык Бистәсе	24165	7734	16431
Биектау	54511	-	54511
Бөгелмә	100093	84925	15168
Буа	39957	19821	20136
Зәй	51877	38486	13391
Кайбыч	12828	-	12828
Кама Тамагы	14342	7424	6918
Кукмара	50227	17699	32528
Лаеш	55530	8789	46741
Лениногорск	79129	60717	18412
Мамадыш	40451	15796	24655
Менделеевск	29273	21606	7667
Минзәлә	26962	16713	10249
Мөслим	18748	-	18748
Норлат	53400	31006	22394
Питрәч	53730	-	53730
Саба	30458	8906	21552
Сарман	33253	12321	20932
Спас	17961	8041	9920
Тәтеш	20524	10601	9923
Тукай	45514	-	45514
Теләче	13571	-	13571
Түбән Кама	275816	254633	21183
Чирмешән	17984	-	17984
Чистай	73766	58228	15538
Чүпрәле	20734	-	20734
Югары Ослан	16052	1177	14875
Ютазы	19676	10516	9160
Яңа Чишмә	12046	-	12046
Яшел Үзән	165726	124080	41646

Ярдәм берләшә

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстанда балалар өчен яшәү минимумы 11 мең 852 сумны тәшкил итә. Пособие күләме шуңа карап билгеләнә. Әлеге ярдәмне кемгәдер – 50, кайберәүләргә – 75, бик авыр хәлдәгеләргә 100 процент итеп түләячәкләр. Саннарга күчерсәк, 5926 сумны, 8889 һәм 11852 сумны тәшкил итәчәк. 17 яшькәчә кадәрге балалары булган кешеләргә пособие 12 айга билгеләнә. Аны алуны дәвам иттерер өчен, ел саен документлар янартып, гариза язып торырга кирәк.

Былел кайбер түләүләрне алучылар икенче елга моны үзләре сайлый. Алар йә элеккеге түләүне ала, йә инде универсаль пособиене сайлый. Очрашуда, бала быелның 31 декабрендә туса, нишләргә, дигән сорауга да җавап бирделәр. Андыйларның да әти-әниләре түләүне үзләре сайлый.

Универсаль пособиенең өстенлеге нидә соң? Ул – хатын-кыз авырлы вакытын башлап, сабые 17 яшь тулганчы түләнә торган ярдәм чарасы. Көмәнлекнең иртә срокларында медицина оешмасына исәпкә баскан хатын-кызга пособие шул көннән башлап, баласы туганчыга кадәр түләнә. Бала тугач, ул инде сабыйга билгеләнә. 3 яшькә кадәрге балалары булганнар берьюлы ике түләү алырга хокуклы. Алар универсаль пособиегә дә өметләнә ала һәм ана капиталыннан да айлык түләүгә рәсмиләштерергә мөмкин.

Киләсе ел башыннан бу пособиене Татарстанда 152 меңнән артык кеше алыр дип фаразлана. Моның өчен федераль бюджеттан – 11,2 млрд сум, Татарстанныкыннан 7,5 млрд сум акча бирелачәк. Аны алу өчен бер генә гариза тапшырырга кирәк булачак. Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы (www.gosuslugi.ru) аша да, күпфункцияле үзәккә яки социаль иминият фонды шәхсән барып та тутырырга мөмкин.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

УНИВЕРСАЛЬ ПОСОБИЕ 6 ТӨРДӘГЕ ЯРДӘМНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ

1. Йөклелекнең иртә срокларында медицина оешмасында исәпкә баскан хатын-кызларга айлык пособие.
2. Вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм эшләмәүче хатын-кызларга бала табуга бәйле рәвештә бирелүче пособие.
3. Беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә балага 3 яшь тулганчы ай саен түләнә торган түләү.
4. 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү.
5. 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларга айлык акчалата түләү.
6. Икенче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә аңа 3 яшь тулганчы ай саен түләнә торган түләү (ана капиталы акчалары исәбеннән федераль һәм төбәк бюджет акчасын җәлеп итмичә бирелә).

АЛТЫН УРТАЛЫК

ЗЫЯН САЛМЫЙ ГЫНА БУЛЫШУ

Авыл тормышы

Тегe яки бу йомышы төшсә, кеше авыл советларына мөрәҗәгать итә. Җир рәсмиләштерү, йортка теркәлү, пай җирләре артыннан йөрү һәм башка шундый мәшәкатьләр күп. Халыкка ярдәм иткәндә алтын урталыкны ничек табарга? Кешегә ярдәм итәм дип, законны ничек бозмаска? Әлеге четерекле сорауларны без авыл советлары башлыкларына бирдек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Зөһрә ГАРИФУЛЛИНА,
Биектау районының Алан Бәксәр авыл җирлеге башлыгы:**

– Җир рәсмиләштерү элек тә бар иде, хәзер дә моның тынып торганы юк. Ләкин ул эшләр бездән китте һәм безгә эш җиңеләйде. Документларны безнең белән килештерү дә кирәкми хәзер. Элгәрәк рәсмиләштермәгәннәр бу эшләргә әле генә тотынырлар. Андыйлар безгә хуҗалык кенәгәсеннән белешмә сорап мөрәҗәгать итә. Ышанычлы булсын өчен, Җир мөнәсәбәтләре палатасына документның күчермәсен төшереп җибәреп, рөхсәт алып кына эшлибез. Торак-коммуналь хезмәтләр буенча да сораулар күп. Әйтик, су сипкән өчен түләү килә. Аның өчен башта бакча мәйданын үлчәп китәләр. Ялгыз гына яшәүче әби дә үч сутый җир өчен түләргә тиеш булып чыга. Шундый очракларда да халык безгә ярдәм өмет итеп килә. Моннан тыш, пенсия яше җитәрәк тегe яки бу кешенең мәгълүматлары буенча Пенсия фонды безгә мөрәҗәгать итә.

Документлар белән эшләгәндә, ялгышмыйча, дөрес карар кабул итәр өчен, тәҗрибә ярдәм итә. Элгәрәк мөрәҗәгать керү белән үк, тизрәк ярдәм итәсе килеп, тиз арада хәл итү ягын карый идем. Хәзер башта юрист, башка белгечләр белән киңәшләшәм, белешәм, законнарны өйрәнәм, шуннан соң карар кабул итәм. Чыннан да, кайвакыт бик четерекле мәсьәләләр килеп чыга. Андый вакытларда ашыгып карар кабул итмим.

Документлар белән эшләү күләме кимеде, әлбәттә. Йортка теркәү-төшүләр дә авыл советы аша эшләнелми бит. Бу, бер яктан, яхшы, икенче яктан, начар. Чөнки без авылда кемнең теркәлгәнен яки теркәлмәгәнен белә алмыйбыз. Мәсәлән, хәзер узара салым буенча җыеннар уздырыла башлады. Бик кирәкле бу мәгълүмат безгә вакытында килеп ирешми, шунлыктан тегe яки бу кеше турында туганнарыннан сорашып беләбез. Бала туу, кеше үлүгә бәйле мәгълүматлар белән дә шулай ук.

Без хәзер күбрәк дәүләт хезмәтләре күрсәтү белән түгел, ә көнкүреш мәсьәләләрен хәл итү белән шөгыльләнәбез. Кемнедер картлар йортына урнаштыру, кемгәдер утын хәстәрләп бирү, кар чистарту һәм башка эшләр.

**Алия ШӘРИПОВА,
Минзәлә районының Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы:**

– Без инде элеккеге кебек, кочак-кочак документлар белән эшләмибез, чөнки барысы да диярлек күпфункцияле үзәкләрдә эшләнә. Ярдәм итеп, киңәш биреп кенә җибәрәбез. Җирләрне теркәү буенча да халык районга мөрәҗәгать итә. Шулай да мирас булып калган мөлкәтне теркәгәндә мөрәҗәгать итүчеләр бар. Хаталары булса, андыйларга дөрес юнәлеш бирәбез. Районда, авылда күп елар чишелеш таба алмаган мәсьәләләр бар иде: кешеләр авыл хуҗалыгы җирләрендә салынган йортларын терки алмадылар. «Камский бекон» җәмгыяте килгәч, әлеге катлаулы сорауның чишелеше табылды. Менә ул да халык өчен яхшы булды. Шунысы бар: гомер буе йомышы төшкән саен авыл советына йөгереп килгән өлкән буын моны аврдан кабул итте. Аңламаучылары, үпкәләүчеләре дә очраштыргалады.

Авыл советларында юристлар юк. Безнең дә бу юнәлештә белемебез юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә катлаулы эшләрне район үзәкләрендәге дәүләт учреждениеләренә хәл ителүгә безгә яхшырга туры.

**Рамил МИНҺАҖЕВ,
Әлки районының Карга авыл җирлеге башлыгы:**

– Без хәзер кешеләргә күпчелек очракта киңәшләр белән генә ярдәм итә алабыз. Четерекле сораулар булганда, төрле белгечләргә шалтыратып белешәбез. Шунысы начар: без хәзер авылда кемнең пропискага кергәнен, кемнең чыкканын да белмибез. Бу зыян авылга. Мирас калдыру да авырлашты. Элек йорт әтиәнисе янында яшәгән төпчек малайга мирас булып күчә иде. Хәзер барысы да нотариус аша эшләнә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

УЯУЛЫК КИРӘК!

БАЛАЛАРГА ТЕРРОРЧЫЛЫК ТУРЫНДА НИЧЕК АҢЛАТЫРГА?

Мөһим сөйләшү

Соңгы арада җанны өркетерлек террорчылык очраклары турында еш ишетергә туры килә. Әледән-әле мәктәпкә йә балалар бакчасына бәреп кереп, кеше үлеменә китергән фаҗигаләр булып тора. Андый вакыйгалар әти-әнидән дә, балалардан да, гомумән, җәмгыятьтән икеләтә уяулык, игътибарлылык таләп итә, билгеле. Балалар белән террорчылык турында ничек сөйләшергә? Гомумән, сөйләшергә кирәкме? Пульмонолог, терапевт Олег Абакумов шуңа бәйле киңәшләре белән уртаклашты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Дәресен генә әйткәндә, иртән уянып, яңалыклар тасмасын карарга да куркыныч. Берниндиі гамәл кылмыйча, кул кушырып утырырга да ярамый. Кечкенә адымнар белән булса да, без нәрсәнедер үзгәртергә тиеш, – ди табиб. – Әйтик, шушы арада булган Ижаудагы очракны гына алыйк. Кеше, кулына корал тотып, мәктәпкә бәреп керде! Бер караганда, бу – алдан фаразлап булмый торган һәм теләсә кайсы мәктәптә булырга мөмкин хәл. Әмма моның психологик ягын да карарга кирәк дип саныйм.

Утсыз төтен булмаган кебек, Олег Абакумов әйтүенчә, мондый очраклар җәмгыятьтәге гомуми агрессия һәм көч кулланы дәрәҗәсенә бәйле. Психологлар да шулай ди. «Дәресен әйткәндә, көн саен диярлек кисәтү булып кабул итәрлек очраклар белән очрашып торабыз. Әмма аларны колак яныннан уздырып та җибәрергә яратабыз. Минем йортым – кырыйда, бу миңа кагылмый дип уйлый күбебез», – дигән фикердә табиб.

Белгеч сүзләренчә, безнең җәмгыятьтә нәрсәдәндер зарлану дәрес гамәл булара кабул ителмәгән. Балаларны да зарланмаска өйрәтеп үстерәләр. «Шуңа да, баланы рәнҗетсәләр дә, ул дәшми. Әмма андый рәнҗетелгәннәр үсеп җиткәч, мәктәпкә корал тотып керә...» – дип борчыла Олег Абакумов.

Балалар белән генә түгел, акылы җитлеккән кешеләр белән дә көч куллану, террорчылык очраклары турында сөйләшү җиңел бирелми. Әмма, табиб сүзләренчә, сөйләшергә мөмкин һәм кирәк тә.

– Көч куллану һәм башка шундый золымнар турында сөйләүдән куркып, сабыйларыбызның күзен дөньяга ачмыйбыз һәм шундый хәлләр килеп чыгарыбыз. Ә бит аларның күпчелеген булдырмый калу да мөмкин иде... Ата-аналар кайбер нәрсәләргә күз йоммаса, үз балалары белән ачыктан-ачык сөйләшсә, билгеле, – дигән фикердә Олег Абакумов.

Белгеч бу җәһәттән түбәндәге киңәшләре белән дә уртаклашты.

– Кагыйдәләр һәм шәхси чикләр турында аңлатырга. Бала башка кешенең чикләрен дә бозарга тиеш түгел, шулай ук үзенекен бозуга да юл куймасын.

– Баланы әләкче, куркак, яла ягучы дип санарга һәм аларга шулай дәшәргә ярамый. Җәмгыять өчен игътибарлы һәм кеше хәленә керә белүчән шәхес үссә, яхшырак бит. Көч куллануның кайсы да җинаять инде ул. Хәтта берәүнең иптәшенең башына китап белән сугуы да! Бу хакта дәшми калырга кирәкми. Усаллыкны иртәрәк күреп, сәбәпләрен иртәрәк юк итәргә мөмкин.

– Балага сораулар бирергә кирәк, борчулары турында белешергә. Әмма артык кайгыртучанлык та күрсәтергә кирәкми. Мөстәкыйльлек һәм тормышка яраклы кеше үстерергә тиеш сез.

Олег Абакумов әйтүенчә, балага мәктәптә ул-бу була калса, үзенә ничек тотарга кирәклеген дә өйрәтергә кирәк.

– Әйтик, мәктәптә атыш башланды, ди. Булдыра алганча, куркыныч тудырган урыннан тизрәк качарга кирәк. Батырлык күрсәтеп, сәбәпләр ачыклап торырга түгел! Мәктәптән мөмкин кадәр ераграк урынга качу ягын кайгыртырга кирәк, шул ук вакытта халык төркеме таптый күрмәсен, – дип аңлата ул. – Йөгерүнең дә үз нечкәлекләре бар. Әйтик, яралану куркынычы кимесен өчен, туры түгел, зиг-заг ясап, төрле якларга авышып йөгерергә кирәк. Куркынычсызрак урынга килеп җиткәч, әтиәнигә хәбәр салырга һәм кичекмәстән 102, 112 телефон номерларына шалтыратып, мәктәптәге хәлне мөмкин булганча тулы итеп аңлатып бирү мөһим. Әгәр дә чыгып китәргә мөмкинлек юк икән, парта, шкаф ише урыннарга качарга тырыш. Кулыңа сакланырга булыша алырлык берәр әйбер алсаң, яхшы. Әйтик, урындык.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Уен гына түгел...

29 октябрьдән укучыларның көзге каникулы башлана. Балаларның да, әти-әниләрнең дә, бармак бөгеп, ялны көткән чагы. Олыларның мәшәкатьле һәм борчулы вакыты булса да, кечкенәләргә ял кирәк. Бер атна җитәрме?

Казанда яшәүче дүрт бала әнисе Диләрә Гыйззәтова бер атна элек үк план төзеп куйган инде.

– Балалар күп булгач, көн тәртибен берничек тә бозып булмый. Әтиләре эштә, экскурсияләргә үзем йөртәм, – ди ул. – Балаларның зурракларына илдәге хәлләрне куркытмыйча гына аңлаттым инде. Икесе 3 һәм 5 нче сыйныфта укый, калганнары кечкенә әле. Берничә көнгә авылга кайтырбыз. Анда ялгыз яшәүче әни көтеп тора. Авылдан килгәч, уен үзәгенә барырга исәп. Укытучылары белән бергәләшеп киного да барасылары бар әле. Шуңа күрә бер көн дә әрәм үтмәячәк. Балалар каникулны бик көтәләр.

Балык Бистәсенең Күгәрчен авылында исә клубта балалар борынгы уеннар уйначак, «Аулак өй», шәл бәйләү, кич утыру күренешләрен күрсәтәчәк.

– Түгәрәкләргә йөрүче балалар белән уеннар, фольклор күренешләре өйрәнәбез, чөнки укыганда вакытлары калмый. Дискотекаларны да яраталар, – ди сәнгать җитәкчесе Чулпан Мингарипова. – Үземнең дә ике кызым бар. Олысы Әдилә – быел 11 нче сыйныфта. Каникул вакытында ул БДИга әзерләнәчәк. Кечесе Алинә – 5 нче сыйныфта. Анысы спортны ярата.

Балтач районының Чапшар авылы клубы мөдире Гүзәлия Вәлиева каникул вакытында яшьләр белән «Көзге бал» кичәсе уздырмакчы.

– Балаларга уйнарга, чабарга, ярышырга, җыйнарга булсын. Шуңа күрә ярышларның күбрәк уздырырга тырышам. Хәзер балаларга аралашу җитми. Минем белән сөйләшергә яраталар. Берәр теманы кузгатсак, аннан тиз генә чыга алмыйбыз. Кичке сәгать 5 тулганда: «Гүзәлия апа, клубка чыгабыздыр бит?» – дип яза башлыйлар. Каникул файдалы үтәр, – ди Гүзәлия Вәлиева.

Каникул вакытында балалар өйдә генә ятмаячак. Теләгәннәр мәктәп яны лагеренда ял итә, төрле түгәрәкләргә йөри ала.

– Каникул вакытында начар яки яхшы укучылар белән генә чаралар уздырмыйбыз һәм бу дөрес тә түгел. Бөтен балага да игътибар җитәчәк. Чараларның күбесе, бүгенге таләпләргә туры китереп, патриотик рухта үтәчәк. Тарихны белү, туган якны ярату бик мөһим. «Көзге бал»дан башлап, укуга кагылышлылары да булачак, – диде Әгерҗе районының мәгариф бүлеге башлыгы Вәсилә Сафиуллина. – Әгәр әти-әниләре риза булса, чиректә бер генә «4ле» яки «5ле» чыккан укучылар белән өстәмә дәресләр оештырачакбыз. Россия халыкларының мәдәни мирасы елы уңаеннан мәктәпләрдә татар, рус, мари, удмурт, инглиз телләрендә тамашалар куелачак. Күрше Удмуртиянең Кече Пурга укучылары белән төрле КВН, чаралар үткәрәчәкбез. Безнең мәктәпләрдә агросыйныфлар эшли. Шул уңайдан әти-әниләр, белгечләр белән авыл хуҗалыгы темасына очрашулар, предприятиеләргә экскурсияләр көтелә. «Пушкин картасы» белән «Иж-Бубый» һәм район музейларына чыгачакбыз.

Сәрия МИФТАХОВА

Белгеч фикере

Айдар АКМАЛОВ,
«Талантларның ачык университеты» башкарма директоры:
– Безнең балалар әле кечкенә. Кызыбызга – 5, улыбызга – 1,5 яшь. Тик шулай да киләсе атнага эшләрне планлаштырдык инде. Ял көннәрендә кызыбызны берничә оешмага алып барырга җыенабыз. Алга таба иҗади юнәлеш табу өчен бу. Һава торышы матур булса, паркларга чыгарбыз, әби-бабайларның хәлен белешербез. Халыклар бердәмлеге көненең тарихын сөйләрбез.
Әти-әниләр балаларына үзләре каникулны ничек уздыруы, берәр кызыклы вакыйга турында сөйләсә дә, файдалы булыр. Һәр җирдә истәлекле урыннар бар. Авыл җирендә, әйтик, кыр казы, кыр үрдәкләренең җылы якка киткәнен карарга мөмкин. Минем өчен бу бик истәлекле вакыйга иде. Шәһәрдә исә паркларга чыгарга була. Хәзерге вакытта кышка әзерлек бара. Зуррак балалар кулларына чүкеч тотып, әти-әниләренә нәрсәдер эшләргә булыша ала. Кичләрен бергәләп өстәл уеннары уйнарга мөмкин. Бер атна ялны да менә дигән итеп уздырырга була бит.

Бер көндә теркәлә

Татарстанда мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләре һәм якын туганнары өчен күчемсез милекне теркәү вакыты кыскарды. Бу хакта кичә «Татар-информ» агентлыгында Росреестр идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова җиткерде.

– Гражданнарның бу категориясе өчен исәпкә алу һәм теркәү гамәлләре бер көн эчендә эшләнәчәк. Моның өчен документларны күпфункцияле үзәккә тапшырырга һәм бер үк вакытта Росреестрның Татарстан идарәсенең теләсә кайсы бүлегенә теркәүне тизләтү турында гариза да бирергә кирәк, – диде белгеч бу җәһәттән.

Аерым алганда, бу мәсьәләне хәл итү өчен Казанда түбәндәге адреслар буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Авангард урамы, 74 йорт, 7 подъезд; Гагарин урамы, 103; Ямашев проспекты, 82; Җиңү проспекты, 100. Республика районнарында исә гаризаны Росреестрның территориаль бүлекләренә тапшырырга мөмкин.

Теркәлүне тизләтү турындагы гариза янында мобилизацияләнүче белән туганлыгны раслаучы документларның күчермәләре дә булырга тиеш. Бу – паспорт, туу турында таныклык, никах турында таныклык. Мобилизацияләнүченең статусын раслау өчен исә повестка, хәрби комиссариаттан алынган белешмә һәм башка шундый документлар да ярый.

Росреестр белгечләре гариза тапшырган кешеләргә күчемсез милекне рәсмиләштергән вакытта килеп чыккан проблемаларны хәл итү өчен ярдәм кулы сузарга әзер, дип белдерде Лилия Борһанова.

Белгеч сүз башында күчемсез милекне теркәү өлкәсендә әле күптән түгел генә булган яңалыкларны да тукталып үтте. Мәсәлән, 29 июньнән теркәлүне раслаучы бердәнбер документ булып бар тик Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры (ЕГРН) биргән өземтә генә санала. Мөһим яңалыкларның тагын берсе – моннан соң Росреестр документларны почта аша җибәрүне туктатачак. Әгәр мөрәҗәгать итүче кулында вакыты чыккан паспорт булса, купфункцияле үзәк аның документларын кабул итүдән баш тарта. Шулай ук документларда карандаш белән генә язылса, ниндидер сүзләр өстәлсә, бозылган урыннар булса да, үзәк хезмәткәре аларны кабул итми. Быел Росреестр хезмәте документларны тулысынча электрон әйләнешкә кертте. Гариза кабул ителгәч тә, ул цифрлаштырыла, кабул итүче белгечләрнең электрон имзасы белән раслана, аннан соң гына Росреестрга җибәрелә. «Нәтиҗәдә документларны теркәү вакыты шактый кыскарды: 9дан 5 көнгә кадәр калды. Чынбарлыкта ул ике көн дә булырга мөмкин», – диде белгеч.

26 октябрьдән мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләре өчен көн саен 9дан 15 сәгатькә кадәр «кайнар» линия эшли башлый. Телефон номеры: 8(843)255-25-71.
Һәр сишәмбедә һәм пәнҗешәмбедә 17дән 20 сәгатькә кадәр «Казан Экспо» күргәзмә үзәге һәм Казан танк училищесындагы җыелу пунктларында белгечләр белән сөйләшеп, үзеңне борчыган сорауларга җавап алырга мөмкин.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«Татар-информ»

КАЗАХЛАР БӘЙРӘМ ИТТЕ

Дуслык

Башкалабыздагы Халыклар дуслыгы йортында гөрләгән бу бәйрәм Казахстан Республикасы көненә һәм Россия белән Казахстан арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрнең 30 еллыгына багышланды.

Тату күршеләр

– Казахстан Республикасы көне 1990 елның 25 октябре белән бәйле, – диде Казахстанның генераль консулы Ерлан Искаков. – Бу көнне Югары Совет Казахстанның бәйсезлеге турында Декларация кабул итте. Шушы вакыт эчендә республикабыз үсте, ныгыды, икътисад өлкәсендә дә көндәшлеккә сәләтле илгә әверелде. Казахстанның тышкы сәяси системасында Россия төп урыннарның берсен алып тора. Дипломатик мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә без стратегик партнерларга әверелдек. Соңгы елларда алып барылган хезмәттәшлек безнең тату һәм тотрыклы күршеләр булуыбызны раслый.

Бәйрәм уңаеннан Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова да котлауларын җиткерде.

– Утыз ел эчендә ике ил арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләр барышында кыенлыклар да булмады түгел. Әмма без үзара аңлашу юлына бастык, – диде ул.

Бәйрәм булгач, әлбәттә инде, сәхнә җыр-биюдән, милли музыкаль инструмент моңнарыннан шау-гөр килеп торды. Казах диаспорасында талантлар искиткеч күп икән. Думбрачылар, «Шатлык» казах халык биюе ансамбльләре, «Гүзәлем» милли киемнәр модасы театры чыгышлары тамашачылар күңеленә бик хуш килде. Соңыннан «шашу» бәйрәме ясап, залда утыручыларның тәм-том белән сыйларга да онытмадылар.

Уртак тарих

Ерлан Искаков җитәкләгән консуллыкка Россиянең 12 төбәге керә: Татарстан, Башкортстан, Мари Иле, Мордовия, Удмуртия, Чувашия республикалары, Киров, Түбән Новгород, Пенза, Свердловск, Ульяновск өлкәләре, Пермь крае. Консуллык ни өчен нәкъ менә бездә ачылган? Ике ил арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрдә республика нинди урын алып тора? Бу сорауларга да җавап таптык. Беренчедән, без – этник яктан бик якын кардәшләр: телебез дә, гореф-гадәтләребез дә бер диярлек. Бүген Казахстанда 200 меңгә якын татар яши (сан буенча алтынчы урында). Татарлар элек казах һәм урыслар арасында сәүдәгәрләр, тәрҗемәчеләр булып хезмәт иткәннәр. Казах далаларына укытучылар, дин әһелләре киткән. Болардың барысы да – ике халыкның уртак тарихы. Без бүген дә Казахстан белән тыгыз хезмәттәшлек итәбез. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та, Казахстан Республикасы башлыгы Касыйм-Җомарт Токаев та гел элемтәдә, очрашып торалар. Казахстан мәдәнияте көннәре сентябрь аенда Казанда да үткәрелгән иде. Шул җәһәттән Казах дәүләт халык инструментлары академик оркестры чыгышын, Казахстан киносы көннәрен республикабыз халкы бик яратып исә ала.

Июль аеннан Казан – Алма-Ата рейслары ачылу да ике республика арасын бик якынайтты. Бу җәһәттән туризм нык үсеш алыр дип өметләнәләр. Бер яктан, Казахстан территориясе төрле кинлекләрдә урнашкан, шуңа күрә анда климат шартлары, ландшафт бик үзенчәлекле. Икенче яктан, Татарстаныбызда да күрсәтерлек әйберләр бихисап.

Икътисадка килгәндә исә әлегә Татарстанга ике ил арасындагы хезмәттәшлекнең биш проценты гына туры килә. Димәк, уйланырга җирлек бар дигән сүз бу. Әлбәттә инде, төп инвестицияләр – индустрия өлкәсендә. Татарстанда казах инвесторларының проектлары урын алган. Мәсәлән, алар арасында Алма-Ата вентилятор заводы бар. Безнекеләр дә кимен куймый. Караганда өлкәсендә – шин заводы, Костанайда кою производствосы шундыйлардан.

Сүз уңаеннан, әле узган атнада гына Казахстан Президенты Касыйм-Җомарт Токаев «Татнефть»нең генераль директоры Наил Мәганов «Достык» (Дуслык) ордены белән бүләкләү турында карар чыгарды.

Бүген Татарстанда бер мең ярым тирәсе казах яши. Аларның күбесе укырга килгән: аеруча техник вузларны үз иткәннәр. Казах студентлары саны буенча Татарстан Россиядә икенче урынны били. Беренчелек – Свердловск өлкәсе кулында, анда ике меңнән артык студент бар. Хәзер инде ике республика арасында югары уку йортларының филиалларын ачу турында да сүз бара.

Мондый бердәмлек аңлашыла да. Ерлан Искаков әйтүенчә, казах белән татар бертуган кебек бит: сөйләмдәге охшашлык җиңел генә аралашырга ярдәм итсә, мәдәният, сәнгать өлкәсендә дә уртак нәрсәләр күп.

Казахларның Татарстандагы диаспорасын Сәгыйть Джаксыбаев җитәкли. Хәтерләсәгез, үз вакытында ул Татарстан халыклары ассамблеясының беренче җитәкчесе иде. Димәк, республикабызда бүгенге халыклар дуслыгының нигезе турыдан-туры казахларга да бәйле булып чыга.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Бәхетле-1» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Латыйпова** Мөслимә Хәбри кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Почет ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 нче шәһәр үзәк клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы урынбасары **Булатова** Фәридә Мәхмүт кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Лука Крымский медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе **Яһудин** Шакир Шахмәт улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
25 октябрь, 2022 ел, № 2/14 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында игълан итә.

Документлар 2022 елның 26 октябреннән 31 октябренә кадәр эш көннәрендә 9.00-18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 б й. (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссияләрен, сайлау комиссияләрен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 17 февраль, 2010 ел, №192/1337-5 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, әнисе **МОРОЗОВА Нинелла Георгиевна** кинәт вафат булу сәбәпле, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы комитеты рәисе Морозов Олег Викторовичның авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе **ХӘБИБУЛЛИНА Эльмира Хәмзә кызы** вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары белән берлектә эшләүне координацияләү идарәсе контроль бүлеге җитәкчесе Хәбибуллин Артур Рәшит улының авыр кайгысын уртаклаша.

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2 КВИТАНЦИЯ
КҮЧЕРМӘСЕН
БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.



П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 31 декабренә кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

Язмышлар ярында

«Улыбызны бик тә гаиләле итәсе килә»

Балтач районының Иске Салавыч авылында яшәүче Светлана һәм Илдус Хәмидуллиннар шулай ди. Сау-сәламәт туып, тәпи китеп, инде тәүге сүзләрен әйтә башлаган, грипп белән авырганнан соң башта ишетү, аннан сөйләшү сәләтен югалткан уллары Илдарның язмышы өчен борчылып, шулай ди алар.

Күп итеп терлек асрап, үз тырышлыклары белән көн күрүче әлеге уңган гаилә турында моннан берничә ел элек язган идек. КФХ оештырып, 50 башка кадәр мөгезле эре терлек асраган еллары була. Бүген инде хуҗалыкларында дүрт сыер һәм җиде бозаулары бар. Күп итеп кош-корт асрыйлар.

– Күпләр, терлек асрауның хәзер бер файдасы юк, ди. Терлек асрап баеп булмый – монысы хак, әмма яшәргә була. Файдасы юк дип кул кушырып утырып та булмый бит, – ди гаилә башлыгы Илдус.

Илдус – шушы авыл егете. Тормыш иптәше Светлана белән ерак Казахстан җирләрендә танышалар, гаилә коралар. Бәхетләрен тулыландырып, уллары Илдар туа. Сау-сәламәт булып туа, тәпи китә, «әннә-əттә», «мәм-мәм» дигән сүзләре белән теле дә ачылып килә. Тик бер яшь тә ике ай дигәндә уллары ангина белән авырып, хастаханәгә эләгәләр. Анда исә грипп белән авыручы балалар күп була. Нәтиҗәдә ангинага грипп та өстәлә һәм грипп дигәнең эзсез калмый: бераздан инде Илдарның эндәшүгә, тавышка игътибар итмәве ачыклана... Шулай да өметләрен өзмиләр, вакытлыча гына булыр, ишетә башлар дип көтәләр. Көтәләр дигәч тә, көтеп кенә утырмый алар. Ике колагы тиң ишетү сәләтен югалткан сабыйларын кайларга гына алып бармый, нинди генә дәвалау курслары үтми Хәмидуллиннар. Кытай медицинасы да калмый, Мәскәве дә... Барысы да өметләндерсә дә, алга китеш күренми. Ишетмәгән бала моңа кадәр әйтә торган сүзләрен дә оныта...

Илдарга ике яшь тулганда гаилә Илдусның туган ягына кайтып төпләнә. 25 ел хуҗалыкта алдынгы шоферларның берсе булды ул. Светасы да, мөмкинлек булуга, фермага, бозаулар карарга керә. Илдарга иптәшкә Рузалия һәм Лилия исемле матур сеңелкәшләр дә алып кайталар. Илдарны якындагы махсус мәктәпләр үзләренә кабул итми, Алабугадагы интернат-мәктәпкә урнаштырырга туры килә. Бу мәктәп турында өлкәннәр бик мактап искә ала. «Сигез ел укыттык, андагы өч ел ике сыйныфка санала, укуын тагын да дәвам иттерәсе килгән иде, тик ара бик ерак, хәзерге кебек машиналар заманы да түгел. Шул сәбәпле Алабугадан Казанга күчергән идек. Анда олырак малайлар каһәрләгән булып чыкты. Безне, улыгыз югалды, килегез, дип чакырттылар, өч тәүлек шундагы подвалда утырган булып чыкты. Монда калмыйм, дип елагач, алып кайттык инде. Шөкер, укый-яза белә, телефоннан үз тиңнәре белән аралаша ала. Ул инде хәзер безнең сөйләмне иреннәрдән укый. Таныш булмаган кешеләр белән аралашканда гына аңлап бетерә алмый», – дип сөйли Света.

Алабугада Илдар укырга-язарга гына түгел, рәсем ясарга да, кул эшләренә дә өйрәнә. Рәсем ясарга сәләте барлыгын белеп, бер рәссам (исемен хәтерләмиләр инде) Илдар белән аерым шөгыльләнә. Монда кайткач, мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында булган күптөрле район конкурсларында катнаша, җиңә дә, призлы урыннар да ала. Кул эшләнмәләре белән дә яратып шөгыльләнә. Хәзер инде күп вакытын маллар янында, бакчада-ихатада эшләп үткәрә.

– Әле Алабугада укыганда ук каникулга кайта иде дә шкафтагы бөтен киемнәрне тәртипләп-пөхтәләп куя. Аннан абзарга чыгып китә, «ай-яй-яй» дип, башын чайкый-чайкый, анда тәртип урнаштыра башлый иде, – дип искә ала Илдус. – Бала чактан бик тә тәртип яратты. Малларны бик ярата. Ашата, җыештыра. Хәзер инде без иртән маллар янына чыкмыйбыз, сеңлесе Лилия белән икесе карыйлар. Җәй буе мотоблок белән яшел печән ташый, әнисенә бакча казырга, яшелчәләр утыртырга булыша. Бер минут тик утырмый ул. Менә бу теплицаны да икәү бергә эшләдек, сварка белән дә булдырып эшли...

– Үзебез исән чакта улыбызны бик тә гаиләле итәсе килә. Бәлки бу язманы укыганнан соң аның белән танышырга теләүчеләр табылыр. – Илдус һәм Света мине әнә шундый теләк белән озатып калды. Хәерлесе насыйп булсын!

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КӨЛДЕРМИ ТОРГАН КОМЕДИЯ

Премьера

Автор белән Цензорның, сәнгать колы һәм система колының, фантазия ирεгε һәм рөхсәт ителгән кысаларның кисешүе нәрсә белән тәмамланыр? Тышкы каршылыкның җиңүчесе булса да, эчке көрәшнең азагы булырмы? Айдар Җаббаров Камал театры сәхнәсендә япон драматургының әсәрен куеп, тарих белән чынбарлыкны кисештерде.

Япон драматургы Коки Митаниның «Көлке академиясе» («Академия смеха») пьесасының сюжеты беренче карашка бик гади тоела. «Көлке академиясе» театр труппасы өчен драматург (Хадзими Цубаки) Токио полициясенең цензура бүлеге офицерыннан (Мацуо Сакисаки) пьесасын сәхнәләштерергә рөхсәт алырга тели. Әсәрдәге вакыйгалар 1940 елның көзендә бара, ә пьеса үзе 1996 елда язылган. Бары ике герой. Ләкин алар – икесе ике төрле дөнья кешесе. Коки Митани әсәрендә система колы һәм сәнгать колы, хаким һәм шәхес, мантыйк һәм хисләр, бәяләүче һәм иҗатчы арасындагы көрәш сурәтләнә.

vk.com/kamalteatr

Спектакль турында

Камал театрының яңа сезондагы беренче премьерасы менә шушы пьеса буенча куелган спектакль булды. Аны күпләргә «Тормышмы бу?», «Агыла да болыт агыла...», «Хуш, авылым» һәм башка спектакльләр аша таныш булган яшь режиссер Айдар Җаббаров куйды. Спектакль «Көл» дип атала. Режиссер сүзләренә караганда, «смейся» түгел, «пепел» дип аңларга кирәк.

Пьесаны Фәнис Җиһанша тәрҗемә иткән. Айдар Җаббаров әйтмешли, гайре табигый, шәп тәрҗемә килеп чыккан. Ут буенча рәссам Ольга Окулованы да билгеләп үтәргә кирәк. Чөнки контрастларга корылган спектакльдә ут үзе бер рольне башкара.

«Көл»дә бары ике актер – Алмаз Борһанов (Цензор) һәм Эмиль Талипов (Автор) катнаша. Айдар Җаббаров пьесаны беренче битләреннән нәкъ менә шушы актерлар тавышы белән укыган, шуңа бу ике рольгә нәкъ менә аларны сайлаган. Тагын бер кызыклы факт: махсус шушы спектакль өчен Эмиль Талипов ярты ел буе барабаннарда уйнарга өйрәнгән. Инде спектакльнең үзенә күчсәк тә буладыр.

Көл...мә!

Әсәрдәге вакыйгаларның кайда һәм кайчан язылганын әйтсәк тә, Айдар Җаббаров моңа берничек тә ишарәләми. «Спектакльне караганда, ничәнче ел икәнен дә, кайсы ил икәнен дә абайламыйбыз. Һәм бу мөһим дә түгел», – ди режиссер үзе. Спектакль Авторны уйнаучы Эмиль Талиповның, сәхнә уртасындагы урындыкка басып, стендап стилендәге монологыннан башлана. Ул төрле илләрдәге сәер законнар турында сөйли. «Ә менә безнең илдә көлү закон белән тыелган», – ди дә, спектакльнең билгеле бер хронотопка «урнаштырылганын» күрсәтә. Көләргә ярамый, әмма Автор «Көлке академиясе»ндә эшли. Көләргә ярамый, әмма Автор комедия язган. Япон драматургының әсәрен шушы рәвешле үзгәртеп, Айдар Җаббаров башыннан ук бөтен ситуациядәге абсурд дәрәҗәсен икеләтә арттыра.

Сәхнә ачыла. Каршыда – Цензорның эш бүлмәсе. Спектакль театрның Кече сәхнәсендә куелгач, тамашачы да шушы бүлмәгә кертеп утыртылган кебек булды. Арткы фонда – пыяла сыман дивар, бер якта – дистәләгән киштәле зур шкаф, аның янында – шредер (кәгазь ваклый торган җайланма). Киштәләрдә – кемнәрнеңдер иҗат җимешләре. Ике сәгать буе сәхнәдә берни үзгәрми диярлек. Бары тик шредер «авыз»ыннан чыккан ап-ак кәгазьләр өеме генә артканнан-арта бара.

Цензор белән Авторның һәр очрашуы шушы бүлмәдә уза. Сигез көн буе театрга бөтенләй йөрми торган Цензор белән даһи драматург «үзгәргән вазгыять»кә туры килә торган пьеса яза. «Ромео һәм Джульетта маҗаралары» берзаман «Гамлет һәм Джульетта маҗаралары»на әйләнә. Чөнки хәзер «гыйшык-мыйшык заманы түгел, гомереңне башка берәү өчен корбан итү заманы». Соңыннан әсәрдә «Императорны Ходай сакласын!» сүзләре пәйда була. Инде дәүләт колы сәнгатьне җиңә дигәндә, бу тарткалашу бөтенләй башка борылыш ала...

Көрәш

Образларны аңларга аларның тышкы кыяфәте һәм күпсанлы детальләр ярдәм итә. Әйтик, Цензорның өстендә – берничә үлчәмгә зуррак ак костюм. Бу да, аны биләп алган предметлар да Цензорның футлярда яшәвенә ишарәли. Автор да үзенә зур булган костюм кигән. Башында – парик. Болар барысы да – саклану чарасы. Аның асыл йөзен без ахырдан гына күрәбез.

Цензорның өенә кергән карга, бер яктан, бу ике образның охшашлыгын күрсәтсә, икенче яктан, Цензорның, бу кошка нәрсә ашатырга икән дип аптыравы кырыс, битараф тоелган геройда да кешелек сыйфатлары барлыгын исбатлый. Бу сыйфатларны Цензор үзе күрми. Аның күзләрен Автор ача. Асылда, Айдар Җаббаровның геройлары әсәр өчен түгел, кеше булып калу өчен көрәшә.

Газиз халкым

«Ә бит бу пьеса татарларга да якын», – ди режиссер. Коки Митаниның бу әсәрендәге фәлсәфәсе, гомумән, берәүгә дә ят түгел. Ә Айдар Җаббаров спектакльне безгә тагын да «якынайткан». Көн белән көн чигендә Цензор да, Автор да рольләреннән чыгып, XX гасырда иҗат иткән татар әдипләренең цензура басымы астындагы яшәешләре турында сөйли. Башта Автор Цензорның бүлмәсендәге вакланган кәгазьләр арасыннан Тукай, Такташның шигырьләрен табып укый. Төп вакыйгалардан бераз читләшеп, без Әмирхан Еники, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Кәрим Тинчурин һәм, гомумән, цензура читләтеп үтмәгән әдипләребезнең тавышларын ишетәбез. Бу аһәңне Виктор Цойның «Моң», «Минем белән син җырлап кара», Зөлфәт Хәкимнең «Җырларым-хыялларым», «Газиз халкым», Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла...» җырлары тагын да көчәйтә. Без «Көл»дә барган вакыйгаларны үзебезнең тарих аша күңелдән үткәрәбез. Эмиль Талипов «Агыла да болыт агыла...» җырын башкарганда, экранда 1930–1950 нче елларда эзәрлекләнгән татар әдипләренең исемнәре пәйда була. Һәм бугазга төер тыгыла.

Шулай итеп, Айдар Җаббаров зур осталык һәм кыюлык белән комедия жанрының төп принцибын тормышка ашыра. Тамашачы башта көлә, ә соңыннан аның күңелен моңсулык биләп ала, ул уйлана башлый. Һәм бу хисләрне спектакльнең нәкъ менә бүген куелуы тагын да арттыра. Әсәрдә сәнгать соңарып кына җиңә, һәм безгә дә күп нәрсәне соңарып кына аңларга туры килә. Иң үкенечлесе әнә шулдыр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТӘРӘЗ ТӨБЕ САЕН... ЯШЕЛЛЕК

Шөгыль

Бакчачылык белән гадәттә олы яшьтәгеләр шөгыльләнә, дисәк ялгышмабыз. Әйтик, әти-әниләр, әби-бабайлар һәм, әлбәттә, үз йорт-җире булган кешеләр. Гадәттә дисәк тә, ул бары тик олыларга гына кызыклы шөгыль дигән сүз түгел. Әйтик, яшьләр дә үз өйләрендә, фатирларда, хәтта тулай торакларда микрояшеллек үстерә икән.

Микрояшеллек турында ишеткәнегез бармы? Сәламәт яшәү рәвешен сөючеләр әлеге сүзне яхшы белә инде. Күп төрле блогерлар аңа аеруча игътибар итә, вегетарианнар туклана, кафе-рестораннар да үз рецептларына кертә.

Белмәүчеләр өчен искәртеп китик. Микрояшеллек йә «microgreen» – инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә «micro» – «бәләкәй», ә «green» – «яшел» дигәнне аңлата. Гадәти аңлауда ул – үсемлекләрнең кечкенә үсентеләре. Бу – тәмләткеч, яшелчә һәм кыяклы культуралар булырга мөмкин. Беренче тапкыр микрояшеллекне космонавтларга ризык өчен кулланганнар дип санала. Ул 1980 нче еллар башында Сан-Францискода популярлаша һәм бөтен Европага тарала. Баштарак микрояшеллек рәвешендә кешеләр руккола, рәйхан, чөгендер, кориандр һәм кәбестә үстергән. Ә инде бүген аның дистәләгән төре бар.

Казан федераль университетының телевидение юнәлеше буенча белем алучы студент Елизавета Русина микрояшеллек белән 1,5 ел дәвамында шөгыльләнә. Ул борчак, көнбагыш, редис һәм кәбестә кебек файдалы культуралар үстереп караган. «Бу миңа бик тә кызыклы, чөнки ашлама һәм химик матдәләрсез генә үзем үстергән файдалы яшелчәләрне ашап карыйсы килде», – дип аңлата ул мавыгуын.

Файдасы дигәннән, микрояшеллек гади яшелчәләрдән икеләтә-өчләтә файдалырак: үзе аз калорияле, витаминнарга, антиоксидантларга һәм магний, бакыр, калий, цинк, тимер кебек микроэлементларга бай. Өстәвенә үсемлекләрнең кечкенә үсентеләрен ашау иммун системага һәм ашкайнату системасына уңай тәэсир итә һәм холестерин дәрәҗәсен дә төшерә. Микрояшеллекне даими рәвештә куллану организмны токсиннардан арындыра һәм күзәнәкләрнең актив яңаруына ярдәм итә.

Елизавета Русина әйтүенчә, бәя ягыннан да яшелчә сатып алуга караганда отышлырак. «Бер төргәк якынча 150 сум тора. Анда 15 кечкенә джут келәме бар. Орлыкны 20–30 сумнан сатып алырга була, ә контейнерлар гадәттә өйдә дә бар», – дип аңлата ул. Димәк, микрояшеллек уңышы алу өчен якынча 15–20 сум акча тотыла.

Ә инде үсемлекнең кечкенә үсентеләрен үстерү өчен бер келәм һәм берничә орлык та җитә, аңа су сибәргә генә кирәк. Якынча бер атнадан соң аны кисеп ашарга була, ә инде яңа уңыш алу өчен, яңадан бер джут келәм һәм орлыклар белән шушы процессны кабатларга туры киләчәк. Шунысын да әйтергә кирәк: микрояшеллек кояшта үсә, шуңа кайберәүләр аның өчен ультрашәмәхә лампа да алып куя.

Тик бу шөгыльнең тискәре яклары да бар икән. Әйтик, барысын да төгәл эшләсәң дә, орлыклар тишелмәскә мөмкин яки үсентеләр кирәкле озынлыкка кадәр үсеп җитмәгән очраклар да була.

КФУ студенты Дмитрий Адеркин быел микрояшеллекнең уңай яклары турында ишетеп, беренче тапкыр аны үстерергә уйлый, әмма ул теләгәнчә килеп чыкмый. «6–7 көн дәвамында руккола кечкенә булып үсте, ул миңа бик аз булып тоелды: бер салатка салдың да шуның белән бетте. Тик хәзер башкасын алып карыйсы килә, әйтик, Вьетнам соя үсентеләрен», – ди ул.

Диана КАРПОВА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары –
ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ,
РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 358

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+